ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Олы Кайбыч ав. № 169

Кайбыч муниципаль районы территориясендә пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем төзү турында

«Россия Федерациясендә пробация турында» 2023 елның 06 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, аларга карата пробация кулланыла торган затларның социаль тәртибен коррекцияләү, ресоциализацияләү, социаль адаптацияләү һәм социаль реабилитацияләү, алар тарафыннан яңа җинаятьләр кылуны кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем булдырырга.

2.Түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем нигезләмәсе (1 нче кушымта);

2.2. Кайбыч муниципаль районы территориясендә пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем составы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында http://kaybici.tatarstan.ru урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026е .26.03 169
номерлы карарына
1 нче кушымта

Кайбыч муниципаль районы территориясендә
пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Кайбыч муниципаль районы территориясендә пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем турында (алга таба - эшче төркем) әлеге Нигезләмә эшче төркем бурычларын, функцияләрен, вәкаләтләрен һәм эшчәнлеген оештыруны билгели. Эшче төркем Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының, кызыксынган территориаль органнарның, федераль башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның Кайбыч муниципаль районында пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча чараларны тәэмин итү максатында килешенгән гамәлләрен тәэмин итү өчен координацион орган булып тора.

Эшче төркем Кайбыч муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау комиссиясе каршында даими нигездә төзелгән һәм эшли.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә пробация турында»2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга, Россия Федерациясе Президентының указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы законнарына һәм башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмә таянып эш итә.

3. Эшче төркем үз эшчәнлеген территориаль органнар, федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кызыксынган оешмалар һәм учреждениеләр белән үзара хезмәттәшлектә башкара.

»

## 2. Бурычлар

Эшче төркемнең төп бурычлары булып пробация кулланылган затларга ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудыру мәсьәләләре тора:

- социаль бәйләнешләрне торгызу;
- һөнәри күнекмәләргә ихтыяҗ һәм эшкә урнаштыру;
- тору урыны бирү;
- белем алу;
- социаль хезмәт күрсәтү хокукын гамәлгә ашыру;

- медицина, психологик һәм юридик ярдәм алу;

- кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау гарантияләрен тәэмин итү.

## 3. Төп функцияләр

Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатыннан эшче төркем түбәндәге функцияләрне башкара:

1. Хөкем ителгәннәрне һәм мәҗбүри эшләр яки иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәзаларны үтәүче учреждениеләрдән азат ителгән затларны яңадан җәмгыятькә яраклаштыру, социаль адаптация һәм социаль реабилитацияләүдә ярдәм күрсәтә;

2. Кайбыч муниципаль районы территориясында эшләүче пробация субъектлары белән җирле үзидарә органнарының процедураларда катнашуын (килешү буенча) һәм аларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

3. Пробация кулланылган затларны ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль реабилитация чараларында катнаштыру өчен (килешү буенча) коммерцияле һәм коммерцияле булмаган, шул исәптән дини, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларны, оешмаларны һәм җәмәгать берләшмәләрен, дәүләтнеке булмаган (коммерцияле һәм коммерцияле булмаган) социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларны, белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларны, фәнни, медицина оешмаларын, шәхси эшмәкәрләрне, шул исәптән пробация субъектлары белән төзелгән килешүләр нигезендә, җәмәгать күзәтү комиссияләрен, шулай ук гражданнарны җәлеп итә;

4. Пробация кулланылган затлар һәм пробация процедураларында катнашучы дәүләт һәм муниципаль органнар арасында мәгълүмати үзара бәйләнешне тәэмин итә (алар арасында мәгълүмат, хатлар, хәбәрнамәләр, мөрәҗәгатьләргә җаваплар, баш тартулар һәм 2023 елның 6 февралендәге 10-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә пробация турында» Федераль закон белән каралган башка документлар алмашу);

5. Җәмгыятьтән изоляцияләнмәгән хөкем ителгәннәр буенча пробация куллану мәсьәләләре буенча эшче төркем карарларының үтәлешен контрольдә тота.

## 4. Хокуклар

Эшче төркемнең төп хокукларына түбәндәгеләр керә:

1. Аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү, аларны үтәүне оештыру;

2. Пробация субъектларыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, оешмалардан (милек формасына бәйсез рәвештә) һәм вазыйфаи затлардан кирәкле материаллар һәм мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә соратып алу;

3. Ведомствоара эшче төркем утырышларында катнашу өчен территориаль органнар бүлекчәләренең, федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук аларның җитәкчеләре белән

килештереп, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләрен җәлеп итәргә.

## 5. Эшчәнлекне оештыру

1. Эшче төркем рәис, рәис урынбасарлары, секретарь, эшче төркем әгъзалары - территориаль органнар, федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләре составында булдырыла.

2. Эшче төркем эшен эшче төркем рәисе җитәкли, ә аның булмаган вакытта - эшче төркем рәисе йөкләмәсе буенча аның урынбасарларының берсе. Эшче төркем утырышы, әгәр анда әгъзаларының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

3. Эшче төркем рәисе:

- эшче төркем утырышларында рәислек итә;
- эшче төркем кабул иткән карарларга кул куя;
- эшче төркемнең чираттан тыш утырышын үткәрү турында, шулай ук чираттагы утырышны күчерү турында карар кабул итә;
- бурычларны эшче төркемнең урынбасарлары һәм әгъзалары арасында бүлә.

4. Эшче төркем рәисе урынбасары:

- эш планы белән билгеләнгән юнәлешләр буенча эшче төркем әгъзаларының эшен оештыра;
- эшче төркем рәисе йөкләмәсе буенча аның вазифаларын башкара;
- җирле үзидарә органнарының кызыксынган органнары һәм учреждениеләре вәкилләре һәм белгечләре арасыннан эшче төркемне җитәкли, муниципаль районның торак пунктларына чыгып, җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек оештыру торышын өйрәнү максатыннан.

5. Эшче төркем секретаре:

- эшче төркем утырышлары беркетмәләрен төзи;
- эшче төркем әгъзаларын чираттагы утырышның урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә;
- эшче төркем утырышында катнашу өчен территориаль органнар, федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм җәмәгать берләшмәләре, эшмәкәрлек җәмгыяте, эшче төркем составына кермәгән фәнни оешмалар вәкилләрен чакыра, көн тәртибенә караган материаллар белән тәэмин итә;
- эшче төркемне шәхси составтагы үзгәрешләр турында хәбәр итә;
- комиссия эшчәнлеге белән бәйле башка йөкләмәләрне үти.

6. Эшче төркем әгъзалары:

- эш төркеме утырышларының көн тәртибенә тәкъдимнәр кертәләр, эш төркеме утырышларына материаллар әзерләүдә катнашалар, шулай ук аның карарлары проектларын әзерлиләр. Утырышта карала торган мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы затлар эш төркеме сәркатибенә кирәкле материаллар һәм карар проектларын тапшыралар;
- муниципаль районның торак пунктларына чыгып, җирле үзидарә органнарының үзара эш оештыру торышын өйрәнү максатыннан кызыксынган

органнар һәм учреждениеләр вәкилләре һәм белгечләре арасыннан эш төркемнәрен җитәкли алалар.

7. Эшче төркем үз эшчәнлеген ресоциализация, социаль адаптация һәм социаль реабилитациягә ярдәм күрсәтү турында гариза кергән саен башкара.

8. Эшче төркеменең эше аның әгъзаларының мәсьәләләрне карауда шәхси катнашуы аша башкарыла. Эшче төркем әгъзасының утырышта катнаша алмау очрагында, аның урынына башка кеше җибәрелергә мөмкин.

9. Эшче төркем утырышларына территориаль органнарның федераль башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать объединенныяләре, оешмалар, эшмәкәрлек җәмгыяте вәкилләре, шулай ук фәнни оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин.

10. Эшче төркем карарлары утырышта катнашучы эшче төркем әгъзаларының күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була. Эшче төркем әгъзалары үзләренең аерым фикерләрен язмача белдерү хокукына ия, ул беркетмәгә теркәлә һәм бу хакта беркетмәдә билгеләп үтелә.

11. Эшче төркем карарлары Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, җирле үзидарә органнарына җиткерелә.

12. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты башкара.

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026е .26.03. 169
номерлы карарына
2 нче кушымта

Кайбыч муниципаль районы территориясендә
пробацияне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшче төркем
СОСТАВЫ

| т/б № | Вазифасы |
|---|---|
| 1 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| 2 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, рәис урынбасары; |
| 3 | Кайбыч муниципаль районының җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге «ФОРПОСТ» МБУ директоры, эшче төркем сәркатибе |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4 | Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| 5 | ТР Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" МКУ начальнигы. |
| 6 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| 7 | Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәте идарәсенең ТР буенча җинаять-үтәтү инспекциясе федераль казна учреждениесенең Кама Тамагы муниципальара филиалы өлкән инспекторы (килешү буенча) |
| 8 | «Кайбыч үзәк район хастаханәсе» ДАССО ның баш табибы (килешү буенча); |
| 9 | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кайбыч муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| 10 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| 11 | Кайбыч районы буенча «РТ Хезмәт базары үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге начальнигы (килешү буенча). |